**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"18" октябрь 2018 ел** **№ 74**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 нчы июнендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында” 62 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 26 июнендәге 62 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче маддәнең унынчы абзацында “капиталь ремонт” сүзләреннән соң “сүтү” сүзе белән тулыландырырга;

1.2. 26 нчы маддәдә:

а) 1 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шәхси торак төзелеше объекты, бакча йорты төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыру таләп ителми. Төзүче үз инициативасы буенча индивидуаль торак төзелеше объектына, бакча йортына карата проект документларын әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы”;

б) 8 нче пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) “Җир кишәрлеген шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә планлаштыру схемасы”;

в) 8 нче пунктның 7 пунктчасында “яки демонтажлау» һәм “яки демонтаж” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8 нче пунктның 10 пунктчасында “капиталь ремонт” сүзләреннән соң “сүтү” сүзе белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендлар аша халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Көрәле авылы, Үзәк ур., 2а;

- ТР, Кама Тамагы районы, Варварино авылы, Ленин ур., 32; шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Варварино авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан РеспубликасыКама Тамагы
муниципаль районы Варварино
авыл җирлеге Советы рәисе Р.Т.Нотфуллин